ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 16 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланың икенче абзацында «(алга таба – гадәттән тыш хәлләр)» сүзләрен «(алга таба шулай ук – гадәттән тыш хәлләр)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:
а) икенче өлештә «оешмалар администрациясе» сүзләрен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче өлеш өстәргә:
«Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мәгълүматны гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы идарә органнарына билгеләнгән тәртиптә үз вакытында тапшырырга тиеш.»;
в) өченче өлешне дүртенче өлеш дип санарга;

3) 9 статьяның беренче өлешендәге дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булганда яисә алар барлыкка килгәндә эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү;»;

4) 10 статьяда:

а) тугызынчы абзацта «, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын уздыру турында карарлар кабул итү һәм шушы чараларны уздыруны оештыру» сүзләрен «турында карарлар кабул итү, гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булганда яисә алар барлыкка килгәндә эвакуация чараларын үткәрүне оештыру һәм гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«федераль, регионара, региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрне юкка чыгарганда гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урыннарында Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның яшәү, гадәттән тыш хәл аркасында тормыш-көнкүреше шартлары бозылу һәм мөлкәте юкка чыгу фактларын билгеләү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 14-ТРЗ